**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.07.2023 № 727

«Нурлат шәһәре территориясендә пиротехник әйберләрне (фейерверк күрсәтүләрне) куллануны тәртипкә китерү чаралары турында» Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 сентябрендәге 894 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе һава киңлегеннән файдалануның федераль кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 11 мартындагы 138 номерлы, «Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карарлары нигезендә, пиротехника әйберләрен кулланып фейерверклар һәм башка массакүләм тамаша чаралары уздырганда кешеләрнең тормыш һәм сәламәтлеген тәэмин итү, муниципаль мелкәткә, юридик һәм физик затлар мелкәтенә зыян китерүне булдырмау максатларында Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 03 сентябрендәге 894 номерлы карары белән расланган Нурлат шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләрдән (фейерверлык күрсәтүләреннән) файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче кушымтаның 6 пунктындагы беренче абзацында «I-III классны» сүзләрен «II-III классны» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2 нче кушымтаның 5 пунктындагы икенче абзацында «пиротехник эшләнмәләр куркынычсызлыгы турында» Таможня берлегенең техник регламенты буенча тиешле хәвефлелектәге I класска туры килә торган шапылдавык һәм бенгаль шәмнәреннән тыш,» сүзләрен тешереп калдырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Сәйфетдинова З.Р.